| Республика Татарстан<br>Совет Шарлиареминского сельского поселения Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Шәрләрәмә авыл җирлеге советы |
|---|---|

Решение Карар

23 май 2022 ел № 46

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карары

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы, «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турындагы нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе хакында» Россия Федерациясе Югары Советы карарының һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында һәм «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның 1 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында» 2021 елның 19 апрелендәге 33 номерлы карары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл жирлеге Советының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында» 2021 елның 06 маендагы23 номерлы карары, Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 декабрендәге 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, карар ителде:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 2013 елның 4 апрелендэге 5 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 36 статьяның 11 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыкларыннан файдалануны чикләү һәм тыю

Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

Торак пунктлар һәм территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау куркынычы тудырырга, тау эшкәртмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның сакланышын да кертеп, биналарның һәм корылмаларның сакланышын булдырырга мөмкин булган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) 27 статьяның 5 пунктындагы 6 пунктча түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) мондый объектны реконструкцияләгән очракта капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, РФ ГК 51 статьясындагы 7 өлешенең 6.2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, күп фатирлы йортны үзгәртеп кору очраклары, блокланган төзелештәге барлык йортларның да хокук ияләренең бер рәттә үзгәртеп кору очрагында ризалыгы»;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы — Н.Н.Хуҗина